**Республика Татарстан**
**Палата имущественных и земельных отношений Заинского муниципального района**

ул.Автозаводская, д.1 А,
г.Заинск, Республика
Татарстан 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы**

Автозавод урамы, 1 а йорт,
Зәй шәһәре Татарстан
Республикасы, 423520
тел. 8(85558)2-80-31,
2-80-32,2-80-33, 2-80-34
E-mail: Pzio.Zainsk@tatar.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«22» 12 2021 ел № 854П

**Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 11 декабрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы

**күрсәтмә бирә:**

1. Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге күрсәтмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Күрсәтмә рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары Г.Ф.Оборинага йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р. Шәйхиев**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «22» 12
854П/номерлы карары белән
расланган.

# Җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

### 1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - административ регламент)җир кишәрлегеннән даими (сроксыз) файдалану хокукын яки җир кишәрлеген гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнеңстандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

### 1.2.Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре

1.2.1. Муниципаль хезмәт алуга хокуклы затлар булып физик һәм юридик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүче) тора.

1.2.2. Гариза белән вәкаләтләрне таныклый торган документ нигезендә эш итүче мөрәҗәгать итүченең вәкиле, яки физик затның законлы вәкиле (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

### 1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү тәртибе

1.3.1.Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (яисә шәһәр округындагы) рәсми сайтында (http://www.zainsk.tatar.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru (алга таба-республика порталы);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (https:// www.gosuslugi.ru (алга таба - бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба - республика реестры) урнаштырыла.

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: